**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**КАРАР**

10 ноябрь 2022 ел | Яңа п. | № 1

Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Яңа Сарайлы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй» авыл җирлеге уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2022 елның 21 ноябренә 16.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Яңа Сарайлы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2023 елда  елда Әҗмәкәй авыл җирлеге Яңа Сарайлы авылында яшәү урыны буенча Әҗмәкәй авыл җирлеге Яңа Сарайлы авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлар һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, Әфганстанда, Чечняда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, Чернобыль атом электростанциясендә аварияне ликвидацияләүчеләр-чернобыльчеләр, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 750 (җиде йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы:

- су челтәрләрен проектлау;
- электроматериаллар сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру

«ӘЙЕ» «ЮК».

3.Әҗмәкәй авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә